РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

БОЛЬШЕШИНАРСКИЙСЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.12.2018 №26-п

Яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәре чорында
Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә
янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү
чаралары турында

Яңа ел бәйрәмнәре чорында, гражданнарның, физик һәм юридик затларның, дәүләт яки муниципаль милекнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «янгын куркынычсызлыгы турында "1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Саба МР КЧС һәм ПБ 10.12.2018 ел № 5-18" номерлы карары нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында» 2018 ел, 7 декабрь, 1088 нче карары һәм Яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәре чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм «Яңа ел»профилактик операциясе үткәрү турында ТР Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карарын игътибарга алырга

2. 2018 елның 20 декабреннән 2019 елның 9 гыйнварына кадәр Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә;

Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда 1-3 классны пиротехник эшләнмәләрне куллануны тыю:

- Сәнәгать объектлары, транспорт инфраструктурасы (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линияле)чикләреннән 500 метр ераклыкта;,

- Торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күп була торган объектлар, автомобиль юллары чикләреннән 50 метр ераклыкта.

3. Олы Шыңар авыл җирлеге учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә янгынга каршы махсус режим кертү турында җиткерү.

4. Әлеге карар нигезләмәләрен, шулай ук пиротехника әйберләрен таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү өлешендә халык, юридик затлар арасында, шул исәптән пиротехника әйберләрен ваклап сатучы юридик затлар арасында аңлату эшләре алып баруны оештырырга.

5. Нормаларга туры китереп, янгын-техник корал белән резерв янгын техникасын тикшерергә һәм комплектларга, исәп-хисапка резерв техникасын кертергә әзер булырга.
6. 2019 елның 2-9 гыйнвар кеннәрендә күп балалы гаиләләр, ялгыз картлар һәм имин булмаган гражданнар яшәү урыннары профилактикасы инструкторлары, ВДПО инструкторлары, ирекле янгын сүндерүчеләр, полиция хезмәткәрләре, халыкны социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре һәм Олы Шыңар авыл башкарма комитеты хезмәткәрләре белән берлектә профилактик тикшерүләр үткәрергә, Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча надзор эшчәнлеге районара бүлекчәсенә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу очраклары турында хәбәр итергә.
7. Полиция бүлекләре, башка күзәтчелек органнары белән берлектә Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларын үткәрүдә катнашкан объектларда янгыннарны һәм аларда кешеләрнең үлемен кисәтү буенча чаралар комплексын оештырырга.
8. Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге учреждениеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә яңа ел бәйрәмнәре чорында дежур персоналның санын арттырырга.
9. Янгын сүндерү техникасы белән ирекле һәм муниципаль Янгын сагы әгъзаларының тәүлек буе кизү торуларын оештыру буенча чаралар комплексын тормышка ашырырга;
10. Олы Шыңар авыл җирлегенең торак пунктларында тенге һәм көндезге сәгатьләрдә ДНД патрульлеген оештыруны тәэмин итәргә. Авыл торак пунктлары территориясендә янгын чыккан очракта кешеләргә хәбәр итү өчен тавыш сигнализациясе чараларын урнаштыруны тәэмин итәргә.
11. Әлеге карарны Олы Шыңар авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://saby.tatarstan.ru/shinar
12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А. Г. Гарипов